ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ШИМБӘ 3 АПРЕЛЬ 1943 ел. № 73 (6795) Аерым номеры 20 тиен.

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

## Кызыл Армиянең кышкы кампаниясенең йомгаклары

*(1942 нче елның 10 нчы ноябреннән 1943 нче елның 31 нче мартына кадәр)*

Кышкы кампания вакытында совет гаскәрләре дошман армияләрен зур хәрби җиңелүләргә дучар иттеләр. Кызыл Армия Сталинград янында немец-фашист гаскәрләргә сугышлар тарихында булган җиңелүләрдән иң зур җиңелүне китерде, Төньяк Кавказда һәм Кубаньда немец гаскәрләрен тар-мар итте, Урта Дон һәм Воронеж районында дошманга күп кенә авыр ударлар ясады, Үзәк фронтта (Ржев—Гжатск—Вязьма) һәм Демянск районында дошман плацдармнарын бетерде, Ленинград блокадасын өзде.

Һөҗүм башланганнан бирле 4 ай да 20 көн эчендә Кызыл Армия гаять авыр кыш шартларында кайбер участокларда 600—700 километрга кадәр көнбатышка таба алга китте. Совет гаскәрләре гаять зур территорияне—480.000 квадрат километр җирне немец илбасарлардан азат иттеләр. Кызыл Армиянең һөҗүме нәтиҗәсендә илебезнең зур экономик һәм хәрби-стратегик әһәмияте булган районнары дошманнан чистартылды. Воронеж һәм Сталинград өлкәләре, Чечен Ингушия, Төньяк Осетия, Кабардино - Балкария һәм Калмык автономияле республикалары, Ставрополь крае, Черкесск, Карачай һәм Адыгей автономияле өлкәләре бөтенләе белән, Краснодар крае, Ростов һәм Курск өлкәләре бөтенләй диярлек, Ворошиловград, Смоленск һәм Орел өлкәләренең шактый өлеше, алардагы дистәләрчә зур шәһәрләр һәм күп меңнәрчә авыллар азат ителде

Кызыл Армия дошманны көнбатышка таба алып ташлап, илебезнең гаять әһәмиятле су юлы һәм тимер юл коммуникацияләрен азат итте, шул исәптән 1942 нче елның көзендә дошман тарафыннан киселгән Волга юлын яңадан ялгады, бөтен Дон буен дошман гаскәрләреннән чистартты. Сталинград—Поворино, Сталинград—Лихая—Ворошиловград, Сталинград—Краснодар, Владикавказ—Ростов-Дон, Лиски—Миллерово—Шахты—Ростов Дон, Елец—Касторная—Валуйки—Ворошиловград, Москва—Вязьма, Москва—Ржев—Великие Луки һәм күп кенә башка тимер юл магистральләре дошманнан азат ителде һәм эксплоатациягә бирелде.

Кызыл Армиянең һөҗүм вакытында, 1942 нче елның 10 нчы ноябреннән 1943 нче елның 31 нче мартына кадәр безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны КУЛГА ТӨШЕРДЕЛӘР: 1.490 самолет. 4.670 танк, төрле калибрдагы 15.860 орудие, 9835 миномет, 30.705 пулемет, 500.000 нән артык винтовка, 17 миллион снаряд, 128 миллион патрон, 123.000 автомашина, 890 паровоз, 22.000 вагон, төрле сугыш милекләре тутырылган 1.825 склад, шулай ук бик күп радиостанцияләр, мотоцикллар һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләре.

Шул ук вакыт эчендә безнең гаскәрләр дошманның 3.600 самолетын, 4.520 танкысын һәм 4.500 орудиесен ЮК ИТТЕЛӘР.

Безнең кышкы һөҗүмебез вакытында дошман барлыгы 5.090 самолет, 9.190 танк, 20.360 орудие югалтты.

1942 нче елның 10 нчы ноябреннән 1943 нче елның 31 нче мартына кадәр 353.525 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

Шул ук вакыт эчендә дошманның үтерелгән солдатлары һәм офицерлары гына да 850.000 нән артык булды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

## Москва, Кремль Иптәш Сталинга

Сезнең җитәкчелегегездәге Кызыл Армиянең, иптәш Сталин, батырлыгы һәм геройлыгы белән фронтка һәрьяклап ярдәм күрсәтергә Сезнең чакыруыгыз белән рухланып, Яңа Писмән районындагы «Уңыш» авыл хуҗалыгы артеленең колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 230 мең сум акча керттеләр. Колхозчылар средствосына төзелгән безнең танкларыбыз фашистик еланнарны сытсыннар һәм юк итсеннәр, колхозның көчен һәм баһадирлыгын ләгънәт фашистларга күрсәтсеннәр.

Колхозчылар исеменнән:
Колхоз председателе ХАФИЗОВ.
Башлангыч партоешма секретаре АКСАНОВА.

## Татарстан АССР. Яңа Писмән районы „Уңыш" колхозы, колхоз председателе иптәш ХАФИЗОВКА башлангыч партоешма секретаре иптәш АКСАНОВАГА

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 230 мең сум акча җыйган «Уңыш» колхозы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганлык сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

## ДОШМАНГА УДАРНЫ КӘЧӘЙТЕРБЕЗ

Мин сугыш башлануга кадәр Ленинград шәһәрендә производствода эшли идем. Сугышның беренче көннәреннән Кызыл Армия сафларына кереп сөекле Ватаныбызны, бөек Ленин шәһәрен немец кабахәтләрдән саклау буенча хезмәт итәм. Ватан сугышы вакытында мин күп нәрсәгә өйрәндем. Үзебезгә тапшырылган коралларны яхшы итеп үзләштердем. Мин үземнең винтовкамнан атып дистәләрчә белофиннарны һәм немец кабахәтләрне юк иттем. Верховный Главнокомандующий иптәш Сталин приказы белән коралланып без дошманга ударны тагын да көчәйтербез һәм аны юк итәрбез.

Иптәш Сталинның приказын намус белән үтәргә, кабахәт дошманны рәхимсез рәвештә кыйнарга, дошманга каршы сугышларда каныммны һәм тормышымны да аямаска ант итәм.

Сержант М. Гарифуллин.

## Совет Информбюросыннан

### 2 нче АПРЕЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче апрельгә каршы төндә фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

☆ Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр үзләренең позицияләрен ныгыттылар һәм разведка алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм бер ротага якын немец пехотасын кырып ташладылар. Икенче бер участокта гитлерчылар төнлә белән үзләренең югалткан позицияләрен кайтарып алырга маташып карадылар. Өлкән лейтенант Дружинин җитәкчелегендәге безнең бер группа сугышчыларыбыз немецларны мылтык һәм пулемет уты белән каршы алдылар. Дошман, тимерчыбык киртәләр янында үз солдатларычың һәм офицерларының 60 үле гәүдәләрен калдырып, чигенде.

☆ Белый шәһәреннән көньяктарак Н-че часть дошманга каршы сугышта 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк итте Танкка каршы ата торган 2 орудие, 7 пулемет, 2 миномет, снарядлар һәм миналар төялгән 6 автомашина кулга төшерелде.

☆ Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр дошманга каршы артиллериядән һәм мылтык-пулеметлардан атып тордылар. Н-че берләшмә частьлары дошман пехотасының атакасын кире кайтардылар. Нәтиҗәдә немецлар зур югалтуларга дучар ителделәр. Икенче бер участокта безнең артиллериябез уты белән дошманның 7 ДЗОТ ы җимертелде, бер сугыш припаслары склады шартлатылды һәм 6 миномет батареясының уты бастырылды.

☆ Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть подразделениеләре, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган 3 пунктны алдылар.

Кичә көндез безнең очучылар безнең бер объектыбызны бомбага тотарга маташкан дошман авиациясенә каршы һава сугышы үткәрделәр. Нәтиҗәдә немецларның 6 самолеты бәреп төшерелде. Шуның өстенә зенит артиллериясе уты белән дошманның 3 бомбардировщигы атып төшерелде һәм 3 бомбардировщигы зарарланды. Шулай итеп, дошманның барлыгы 9 самолеты юк ителде һәм 3 самолеты сафтан чыгарылды.

☆ Ленинград өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның җәза экспедициясенә каршы сугышта берничә дистә гитлерчыны юк иткән һәм трофейлар кулга төшергән. Ленинград өлкәсе партизаннарының икенче бер отряды дошманның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз һәм төрле сугыш йөкләре төялгән 16 вагон җимерелгән.

☆ Көнбатыш фронтта немецларның 267 нче пехота дивизиясенең 487 нче полкыннан бер группа солдатлар плен алынды. Пленныйлардан солдат Генрих Финэ, обер-ефрейтор Вернер Дунклер, фельдфебель Альберт Пеплау болай диделәр: «Без Большая Каменка авылында оборонада торабыз. 6 нчы ротага ничек кенә итеп булса да үзенең позицияләрен саклап калырга приказ бирелде. Ләкин без каршы тора алмадык, руслар авылга бәреп керделәр һәм аны алдылар. Бер көн эчендә генә дә ротаның 75 кешесе үтерелде. 1 нче, 2 нче, 5 нче һәм 7 нче роталар аеруча зур югалтуларга дучар булдылар. Рота командиры лейтенант Штеменк һәм Гофман, обер-лейтенант Гаупнер һ. б. үтерелделәр. 6 нчы ротадан барлык офицерлар стройдан чыктылар. 487 нче полкның күп кенә подразделениеләре бөтенләй беттеләр». Шул ук полкның 7 нче ротасыннан плен алынган солдат Курт Гейнерт болай диде: «Сталинград янында Паулюс армиясенең тар-мар ителүе турында солдатлар һәрвакыт сөйләшәләр. Хәзер инде солдатлар, Сталинград янында 6 нчы армия төшкән хәлгә төшмәсәк ярар иде, дип куркалар».

☆ Германиянең Магдебур шәһәре якынындагы ике заводта хәрби кабул итү комиссиясе уртача авырлыктагы 45 танкны һәм 68 зенит орудиесен брак дип тапкан. Комиссия бу яраксыз техниканы металл ватыгы итеп файдаланырга тәкъдим иткән. Гестапочылар бу предприятиеләрдә эшләүче бельгияләләр, французлар, итальяннар арасында күп кешеләрне кулга алган. Берничә көн үткәч, заводтан 86 чит ил эшчесе качкан. Алар качар алдыннан үзләренең станокларын яраксыз хәлгә китергәннәр.

### 2 нче АПРЕЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче апрельдә фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Баренц диңгезендә безнең корабельләр дошманның барлыгы 15.000 тонна авырлыктагы ике транспортын батырдылар.

☆ 1 нче апрельдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән кимендә 40 автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар, 10.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

☆ Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган чикләрне ныгыттылар һәм аерым участокларда җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, дошманның көчле ут каршылыгын җиңеп, немецларны зур әһәмияте булган бер терәк пункттан бәреп чыгардылар. Дошманның 2 артиллерия һәм 3 миномет батареясы, ике ротага якын пехотасы юк ителде.

☆ Белый шәһәреннән көньяктарак дошман белән атыш булды. Н-че часть артиллеристлары, уңышлы ут һөҗүме ясап, дошманның 300 гә якын кешедән торган бер пехота колоннасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр. Икенче бер участокта совет артиллеристлары дошманның 2 артиллерия батареясының, алты көпшәле бер миномет батареясының утын бастырдылар, 8 ДЗОТ ын һәм блиндажын җимерттеләр. Н-че часть снайперлары бер көн эчендә 74 гитлерчыны юк иттеләр.

☆ Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр үзләренең позицияләрен яхшырттылар, ә гаскәрләрнең бер өлеше дошманның атакаларын кире кайтарып торды. Бер участокта немецлар пехотасы, танклар ярдәме белән, һөҗүмгә күчкән иде. Н-че берләшмә сугышчылары дошманның атакаларын кире кайтардылар һәм аны авыр югалтуларга дучар иттеләр. Сугышлар элекке чикләрдә дәвам итә.

☆ Фронт участокларының берсендә чех-словакларның полковник Свобода командалыгында СССР да төзелгән хәрби часте уңышлы хәрәкәт итә. Н. шәһәреннән көньяктарак бу частьның сугышчыларына дошманның 60 танкысы һәм автоматчиклары атака ясаган иде. Чехсловак часте сугышчылары бер көн һәм бер төн буена, үз-үзләрен аямыйча, дошманга каршы көрәш алып бардылар һәм гитлерчыларның барлык атакаларын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә немецларның 19 танкысы зарарланды һәм яндырылды, 400 гә якын немец автоматчиклары юк ителде. Чех-словаклар частеның икенче бер подразделениесе немецларның һөҗүмен тоткарларга задание алды. Чех словак часте сугышчылары һәм командирлары, совет гвардеецлары белән бергә хәрәкәт итеп, немецларның 3 танкысын юк иттеләр, дошманның күп кенә җанлы көчләрен кырдылар һәм командование тарафыннан куелган хәрби бурычны үтәделәр.

☆ Дошман авиациясе Батайск шәһәренә һөҗүм итәргә маташып карады. Совет истребительләре дошманның юлын тоткарладылар һәм һава сугышында немецларның 4 бомбардировщигын бәреп төшерделәр.

☆ Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның җәза экспедициясенә каршы сугышларда 200 гә якын гитлерчыны кырып ташлаган. 14 нче мартта Минск өлкәсе партизаннары дошманның бер хәрби эшелонына кыю һөҗүм ясаганнар. Совет патриотлары бер паровозны һәм 10 классный вагонны юк иткәннәр. Мылтык һәм пулемет уты белән 130 дошман солдаты һәм офицеры яраланган һәм үтерелгән.

☆ Дошманның сакчы частьларыннан бер группа словак солдатлары партизаннар ягына чыкканнар. Словаклар болай дигәннәр: «Без — резервтагы словак дивизиясе солдатлары. Әлегә кадәр Белоруссиядә идек һәм анда тимер юлларны, күперләрне һәм башка объектларны саклап тора идек. Совет кешеләренә карата немецлар колак ишетмәгән ерткычлыклар һәм кабахәт җинаятьләр эшләделәр. Без чехларның һәм словакларның юлы немецлар белән түгеллеккә ышандык. Без аларга авылларны яндыруда һәм гөнаһсыз балаларны, хатын-кызларны һәм картларны атуда булышлык итәргә теләмибез. Бөек славян халыклары семьясы уллары буларак, без партизаннар ягына чыктык һәм алар белән бергә көрәшеп, тирән тылда немецларны кыйныйбыз, фашист илбасарларны юк итүдә Кызыл Армиягә ярдәм итәбез. Монда, Белоруссиядә, без славяннарны фашизм коллыгыннан азат итү өчен, азат һәм бәйсез Чех-Словакия өчен көрәшәбез».

☆ Югославия партизаннары Гламоч, Невесине һәм Калиновик шәһәрләрен алганнар. Невесинене саклап торган итальян гарнизоны тар-мар ителгән, ә калдыклары тәртипсез рәвештә чигенгән. Патриотлар күп трофейлар кулга төшергәннәр. Ловинац месточкасы янындагы бик каты сугышларда гитлерчыларның 300 дән артык солдат һәм офицерлары үтерелгән һәм яраланган. Партизаннар немецларның 3 танкысын юк иткәннәр, 2 орудие һәм башка кораллар кулга төшергәннәр. Партизаннарның Кониц шәһәре янындагы ныгытмаларын дошманның өзәргә маташулары барысы да уңышсыз чыккан. Партизаннар 35 көн буена дошманның күп санлы атакаларын уңышлы рәвештә кире кайтарып торганнар һәм аны авыр югалтуларга дучар иткәннәр. Оккупантлар, Югославия патриотларына каршы көрәштә уңышка ирешә алмыйча, чигенергә мәҗбүр булганнар.

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ НАКАЗЫН НАМУС БЕЛӘН ҮТӘРБЕЗ

## *Татар халкына Ленинград фронтындагы фронтовик татарларның җавап хаты*

Кадерле аталарыбыз, аналарыбыз, туганнарыбыз, хатыннарыбыз! Фронтовик татарларга язган хатыгызны тирән канәгатьләнү белән укып чыктык. Безнең һәрберебез аны үз өеннән килгән хат дип карады.

Безнең өскә данлы бурыч—Ленин шәһәрен—революциянең бишеген саклау бурычы йөкләнде. Барлык сугышчылар белән—руслар һәм украиналылар, белоруссылар һәм грузиннар, казаклар һәм үзбәкләр белән бер сафта торып көрәшкән хәлдә без немец кабахәтләрне туктаусыз кырабыз, дошманның техникасын җимерәбез, дошман яуларын Ленинград яныннан куабыз.

Немец илбасарларга каршы ватан сугышы 20 айдан артык дәвам итә инде. 20 айдан артык вакыт буена без җиребезнең һәрбер карышын саклап киләбез, үзебезнең азатлыгыбызны, үзебезнең шәһәрләребезне, үзебезнең авылларыбызны, үзебезнең гаиләләребезне саклап киләбез.

Немец-фашистлар безнең йортларга, безнең байлыкларыбызга хуҗа булырга теләделәр, безнең хатыннарыбызны, аталарыбызны, аналарыбызны, немец бароннарына кол итәргә теләделәр. Бу беркайчан да булмас. Без, туган җиребезнең һәрбер карышын, үзебезнең тормышыбызны һәм каныбызны кызганмыйча сакларга Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинга ант иттек.

Без, татар сугышчылары, үзебезнең антыбызны намус белән үтибез. Татар сугышчылары немецларны коралларның барлык төрләре белән кыйныйлар, аларны пушкалардан, миномётлардан, пулеметлардан винтовкалардан атып кыралар, танклар белән таптаталар, самолетлардан өсләренә бомбалар яудыралар.

Атаклы снайпер Нәҗип Хәкимов турындагы дан бөтен фронтка яңгырый. Йөрәгендә кабахәт илбасарларга карата көчле нәфрәт уты янган бу батыр егет 123 немец оккупантны кырып ташлады. Батыр укчы, снайпер З. Юсупов 119 фашист кабахәтне юк итте. Өлкән сержант, танкист Мидхәт Альбеков ике көн эчендә генә дә үз пулеметының уты белән 78 немецны үтерде. Аның сугыш машинасы дошманның 12 блиндажын туздырып ташлады.

Ленин шәһәре блокадасын өзүдә күп кенә батыр һәм оста татар сугышчылары катнашты. Гвардияче пулеметчы ефрейтор Х. Газизуллин, геройларча сугышып, бер сугышта 50 фрицны юк итте. Х. Газизуллин «Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнде.

Гвардияче кызылармеец, артиллерист Ибраһим Нәбиуллин, үз пушкасыннан туры атып, 30 немецны кырып ташлады һәм дошманның танкка каршы ата торган орудиесен җимерде. Гвардияче кызылармеец, пулеметчы Мөхәррәм Кутузов бер сугышта гына да 25 фашистны кырды. Нәбиуллин һәм Кутузов иптәшләр «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнделәр. «Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнгән артиллерист-наводчик Сәхап Садретдинов геройларча хәрәкәт итте. Ул, үз пушкасыннан берничә снаряд җибәреп, дошманның бер ДЗОТ ын һәм бер пушкасын прислугасы белән берлектә тар-мар итте, 80 немецны кырды.

Кеше ашаучы немецларга каршы лейтенант Нефедкин һәм ефрейтор Абдуллиннар пәһлеваннарча сугышалар. Немецларның 3 ДЗОТ ы безнең һөҗүм итеп алга баручы гаскәрләребезнең юлын бикләгән иде. Лейтенант Нефедкин һәм ефрейтор Абдуллин, гранаталар алып, дошманның ут нокталарына шуышып бардылар һәм икәүләшеп немецларның 3 ДЗОТ ын юк иттеләр, кораллар һәм сугыш припаслары кулга төшерделәр, үз подразделениеләренә юл ачтылар.

Кадерле якташлар! Заводларда, фабрикаларда, совхозларда, колхозларда сезнең Ватан хакына стахановча эшләвегез безне дошманга каршы көрәштә рухландыра. Без, фронтовик татарлар, бөтен Советлар Союзы шикелле үк, Татарстанның да Кызыл Армияне барлык кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итеп торганлыгын беләбез.

Сезнең үз-үзегезне аямыйча эшләвегез безнең җиңүебезне тизләтә һәм якынайта. Нева ярында, Ленинград янында, без сезнең Волгада ирешкән уңышларыгызны шатлык һәм горурлык белән күзәтеп торабыз.

Без сезне киләчәктә дә стахановча эшләргә өндибез. Фронтка коралларны һәм сугыш припасларын, икмәкне һәм башка продуктларны күбрәк бирегез. Сез эшләгән һәрбер снаряд, сез биргән һәрбер пуля, сез үстергән ашлыкның һәрбер килограммы—дошманга удар.

Сез безгә нык торырга, арсланнар кебек сугышырга наказ бирдегез. Без ант итәбез: Ватан каршындагы изге бурычыбызны намус белән үтәрбез, каныбызны да, көчебезне дә, тормышыбызны да кызганмабыз.

Немец илбасарларга каршы бездә нәфрәт көчле. Без тормышны яратабыз, бәхетле Ватаныбызны, гаиләбезне, балаларыбызны, Татарстаныбызны яратабыз һәм шуңа күрә дошманнарга нәфрәт белән карыйбыз. Без Волга буеның иркен сәхраларын, Кама буйларын, болыннарны, урманнарны, бөек елгабыз Иделне, туганыбыз Казаныбызны яратабыз. Шулар өчен, бөек анабыз—Ватан өчен батыр татар егетләре ярсуланып һәм куркусыз сугышырлар, дошманны Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы, туганыбыз иптәш Сталин кушканча кыйнарлар.

Ленинград фронтының фронтовик татарлары исеменнән хатка кул куйган сугышчылар һәм командирлар: Г. Габҗәлилев, орденлы Н. Насруллаев, К. Ганиев, орденлы К. Аксаков, С. Хуҗин, Ф. Фәйзуллин, В. Иляков, А. Хәбибов, З. Исхаков, И. Ситдиков, орденлы Г. Әхмәдуллин, Г. Ненмасов, И. Мугафуров, Ишмуратов, К. Юлдашев, Г. Фәхретдинов, С. Зәйдулов, А. Солтанов, Г. Вәлиуллин, М. Хантимиров, А. Закиров, Г. Гайнуллин, А. Нәриманов, С. Нигъмәтҗанов, Т. Яһудин, Х. Зарипов, М. Әмирбаев, Ваһапов, С. Муллагалиев, Х. Арбузов, И. Латыйпов, М. Хәйруллин, Тинчурин, Х. Алиев, А. Низамов, Ш. Гаязов, Я. Янгузин, Я. Мөхәметов, М. Сәлахов һәм башкалар—барлыгы 513 кеше.

## АНЫҢ ОРУДИЕСЕ 9 САМОЛЕТ БӘРЕП ТӨШЕРДЕ



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Ильмен күленнән көньякта). РӘСЕМДӘ: зенит орудиесе новодчигы кече сержант Фәтхи Әхметшин. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен ул Кызыл байрак ордены белән бүләкләнде. Аның орудиесе дошманның 9 самолетын атып төшерде инде. иптәш Әхметшин сугышка кадәр Татарстн АССР ның Казанбаш МТС ында тракторчы булып эшләгән иде. ТАСС фотохроникасы.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ УРНЫНДА

## Стена газетасының эше бүгенге сораулар югарылыгына

Стена газетасы—ул, большевистик матбугатның гаять әһәмиятле буыны. Изге ватан сугышы чорында аның роле тагын да үсте. Явыз дошманны тизрәк тар-мар итү өчен фронтка һәрьяклап ярдәм итүдә большевистик матбугат һәм шул исәптән стена газеталары үзләренең коллектив агитатор һәм пропагандист, массаны коллектив оештыручы булучанлыкларын берничә кат арттырырга тиешләр.

Һәрбер стена газетасы үзенең эчтәлеге һәм оформлениесе белән шушы бурычны уңышлы үтәүгә хезмәт итәргә тиеш. Ләкин күп кенә стена газеталары әле хәзергә чорда үзләренә төшкән бурычларны үтәүдән ерак торалар. Ютазы районы колхозларында чыга торган байтак кына стена газеталарының эше белән танышканнан соң шундый нәтиҗәне ясарга туры килә. Аларның эшендә күп кенә җитди кимчелекләр бар. Бу кимчелекләр—редколлегия членнарының барысы да газетаны чыгаруга актив катнашмауларына, кайбер урыннарда исә сайланып куелган редколлегиянең бөтенләй булмавына, стена газетасы тирәсенә колхозчылардан актив тупланмауга кайтып кала. Ниһаять, әнә шуларның нәтиҗәсе буларак, колхозның көндәлек эшенә һәм колхозчыларның культура-көнкүреш мәсьәләләренә бәйләнешле материаллар стена газеталарында бик аз урнаштырыла. Шуңа күрә газета кызыксыз чыга, большевистик матбугатка хас булган эшлекле тәнкыйть булмый.

Ворошилов исемендәге колхозда чыга торган стена газетасының беренче номерында газетаның яртысына баш мәкалә, калган өлешенә исә кыска гына дүрт хәбәр урнаштырылган. Шуларның өчесе төрле җитешсезлекләр турында языла. Бу хәбәрләрнең эчтәлегенә килгәндә, аларны газетада урнаштыру белән урнаштырмау арасында аерма бик кечкенә. Мәсәлән, «Тәртипсезлек көчле» дигән хәбәр болай дип язылган:

«Ындырда ашлык сугучыларның кайберләре ашлык сугу өчен барып та, ындыр мөдиренең рөхсәтеннән башка, бау белән корма алу өчен генә баралар. Бу эш киләчәктә колхоз малларын ач калдырып һәлакәткә төшерәчәк. Мондый һәлакәттән һәркем сак булырга тиеш».

Ындыр табагыннан кемнәр рөхсәтсез салам алып кайтканнар һәм кайчан? Хәбәрдә әнә шул сорауларга урын калдырмаслык фактлар конкрет күрсәтелергә тиеш иде.

«Калияр» колхозы янында чыга торган «Колхозчы» газетасының беренче номерында баш мәкалә газетаның 75 процентын биләп тора. Калган урынга колхозның беренче бригадасында атларга начар карау турында бер хәбәр урнаштырылган һәм әнә «Беренче бригаданың атлары» дип имза куелган. Әйтерсең лә, хәбәрне атлар үсемнән язмасан, колхозда бу хәбәрне үз җаваплылыгына алырдай беркем дә юк! Аннары бер-ике хәбәр урнаштырырлык ак калган урынны газетаны чыгаручы кәкре сызыклар ясап тутырган. Гүя колхозда шушы урынны тутырырлык та хәбәр «табылмаган».

Менә мондый җитешсезлекләр һәм хәбәргә ярлылык башка колхозларда һәм бригадаларда чыга торган стена газеталары өчен дә характерлы.

Язгы кыр эшләре якынлаша. Бу чорда стена газеталары үзләренең эшләрен берничә тапкыр яхшыртырга тиешләр. Моның өчен, барыннан да элек, редколлегия составына сайлаулар үтмәгән урыннарда колхозчыларның һәм бригада членнарының гомуми җыелышларында колхоз, бригада стена газеталарының отчетларын тыңларга һәм редколлегиягә сайлаулар үткәрергә кирәк. Газетаны эчтәлек һәм оформление ягыннан яхшы чыгару өчен редколлегиянең һәрбер членына конкрет бер эш йөкләтелгән булырга тиеш. Язгы чәчүне уңышлы үткәрү эшенә, 1943 елда югары иген уңышы алу өчен көрәшкә массаны туплау — колхоз, МТС, совхоз, бригада стена газеталары өчен үзәк мәсьәләләрнең берсе һәм иң актуаль тема. Газета бу эштә булган уңышларны һәм алдынгыларның тәҗрибәләрен башкалар үрнәк алырлык рәвештә тулы яктыртырга, эшне таркатучыларны, булдыксызларны фаш итәргә һәм аларны большевистик матбугатка хас булган үткен тел белән тәнкыйть итәргә тиеш. Хәбәрләрне кыска, аңлаешлы тел белән, грамоталы язу, газетаны матур оформить итү, лозунгларны һәм хәбәр башларын сайлый белү, карикатура һәм рәсемнәр урнаштыру—болар барысы да газетаның авторитетын күтәрүдә, үз тирәсенә массаны туплауда гаять әһәмиятле урын тоталар. Редакциягә карикатура һәм рәсемнәр урнаштырылган бер генә сигнал да нәтиҗәсез калмасын. Башлангыч партоешмалар, алар булмаган урыннарда комсомол оешмалары, стена газетасының эшенә көндәлек җитәкчелек һәм булышлык тәэмин итәргә, колхоз производствосында эшне оештыру һәм уңышлы үткәрүдә большевистик матбугатның көченнән тулысынча файдаланырга тиешләр.

# ТАТАР ХАЛКЫ ФРОНТТА һӘМ ТЫЛДА

Гитлерчы кабахәтләр, безнең илебезгә каршы сугыш башлаганда үзләренең күп исәпләреннән берсе итеп, СССР дагы төрле милләт халыклары арасында таркалу, үзара ызгыш килеп туар дип тә исәп тотканнар иде. Кеше ашаучы фашистларның бу ахмак исәпләре дә барып чыкмады. Илебезнең барлык халыклары явыз дошманга каршы, сөекле Ватан өчен бердәм булып изге көрәшкә күтәрелде.

Немец фашистларның кыргый ерткычлар икәнлеген, СССР халыкларын кол итәргә, кырып бетерергә теләгәнлекләрен һәм вакытлыча оккупацияләнгән совет районнарында алар үзләренең бу коточкыч планнарын тормышка ашыра барганлыкларын азатлык сөюче татар халкы бик яхшы белә, күрә. Шуның өчен дә ул үзенә чын ирек биргән Совет Ватанын саклауда, явыз дошманны тар-мар итүдә алгы сафларда булып көрәшә. Татар халкы үзенең улларын фронтка озатканда:

—Совет кешеләренең һәрбер тамчы каны өчен, һәрбер күз яше өчен, һәрбер киселгән гомер өчен син немецтан үч ал! Үтер немецны! — дип наказ бирә.

Татар халкының фронтовик татарларга язган сәлам хатында аның барлык уйлары, теләкләре бик көчле һәм тирән тәэсирле итеп чагылдырылган. Бөек Ватан сугышының барлык фронтларында һәрбер татар сугышчысының күкрәгендә саклана торган бу хат, ватанга, үз халкына мәхәббәт, дошманга нәфрәт хисләрен тагын да көчәйтеп, сугышчы өчен яңа, куәтле корал хезмәтен үти.

Без бүген газетабызда, Ленинград фронтында сугышучы татар фронтовикларының хатын басабыз. Татар халкының сәлам хатына җавап булган бу хатның һәрбер юлы, һәрбер сүзе бөек изге ант булып яңгырый. Фронттагы татар егетләре үзләренең бу хатларында: «Изге ватаныбызның һәрбер карыш җирен без үз каныбызны һәм тормышыбызны да аямыйча сакларга дип Ватаныбызга, Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинга ант иттек», дип язалар. Һәм алар үзләренең бу антларын намус белән үтиләр. 123 фашистны үтергән снайпер Нәҗип Хәкимов, 119 фашистны үтергән снайпер З. Юсупов, пулеметтан атып 78 фашистны үтергән һәм үз машинасы белән дошманның 12 блиндажын сытып изгән танкист Мидхәт Альбеков, сугышта искиткеч батырлыклар күрсәткән орденлы пулеметчы Газизуллин, тупчы Нәбиуллин, Садретдинов, лейтенант Абдуллин һәм башка бик күп безнең данлыклы якташларыбыз татар халкының сәлам хатына шулай сугышчан эшләр белән җавап бирәләр. Лекин шәһәрен, Октябрь Революциясе бишеге булган шәһәрне саклауда, Ленинград блокадасын өзү сугышларында катнашу бәхтенә ирешкән бу улларыбыз белән без хаклы рәвештә горурлана алабыз.

Ленинград фронты батырлары, үзләренең сугышчан эшләре турында үз халкына хисап бирү белән бергә, безне үз постыбызда, — завод һәм фабрикаларда, колхоз һәм совхозларда, — шулай ук армый-талмый, геройларча эшләргә, фронт өчен коралларны, сугыш припасларын, азык продуктларын күбрәк һәм күбрәк бирергә чакыралар.

Тыл фронтка бурычлы булып калмас. Ленинград фронтында сугышучы татар егетләренең бу хаты һәрбер эшчедә, һәрбер колхозчыда яңа хезмәт энтузиазмы тудырыр.

Предприятиеләрдә эшләп чыгару планнарын арттырып үтәү, Май алды ярышын киң җәелдереп, Кызыл Армия Баш Командованиесенең куәтле махсус фондын төзү, колхоз кырларында язгы чәчүгә әзерлектә һәм аны үткәрүдә хезмәт батырлыгы үрнәкләрен күрсәтү, бьюл югары хәрби уңыш яулап алу — Ленинград фронтында сугышучы татар егетләренең бу хатына безнең җавабыбыз шул булырга тиеш.

# Язгы чәчүне отлично әзерлек белән каршылыйк!

*Тик яхшы орлыклар гына чәчелүен, язгы кыр эшләренең иң кыска срокта үтәлүен тәэмин итик, быел иң югары иген уңышы алуга ирешик! Бу—фронтның тылга булган иң әһәмиятле наказы икәнлеген хәтердән чыгармыйк!*

## БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

### БАШ КОМАНДОВАНИЕ ФОНДЫНА

Партком секретаре урынбасары иптәш Козлов булган завод коллективы март ае программасын уңышлы тәгәлләде. Заводның кайбер цехлары программаны срогыннан элек үтәп, Кызыл Армиянең Баш Командованиесе фондына күп кенә өстәмә продукция эшләп чыгардылар. Мәсәлән, начальнигы иптәш Лизунов булган цех айлык планны 29 нчы мартта ук үтәде. 30—31 нче мартларда цех коллективы, Баш Командование фондына эшләп, өстәмә рәвештә 16 изделие бирде.

Начальнигы иптәш Сорокин булган цех коллективы да март аенда өстенә алган барлык йөкләмәләрне үтәп чыкты. Бу цех коллективы апрель ае программасын 25 ендә тәгәлләргә сүз бирә.

Г. ХАЛИТОВА.

—◇—

### ҮРНӘК БРИГАДА

«Спартак» комбинатында Май алды социалистик ярышы көннәнкөн киңрәк җәелә бара. Унт цехы ярышта алдынгылардан санала. Бу цехның начальнигы иптәш Смирнов, моңа кадәр яраксыз дип саналган хром һәм олтанлык калдыкларыннан файдаланып, яхшы сыйфатлы аяк киемнәре эшләп чыгаруны оештырды. Шуның белән бергә, иптәш Смирнов балалар йортларында тәрбияләнеп чыккан үсмер кызлардан бригада оештырып, аның эшенә уңышлы җитәкчелек итә башлады. Бу бригада производство заданиеләрен 130 проценттан алып 165 процентка кадәр үти.

Мастер иптәш Бикбатыровның кисү-әзерләү бригадасы да мартның соңгы көннәрендә иң яхшы сыйфатлы продукция бирүе белән үзен бөтен комбинатка танытты.

И. ТУКТАРОВ.

—◇—

### Иптәш Шакированың уңышы

Март ахырларында начальнигы иптәш Кононов булган цехның мастер Исфин семьясында бөтен заводны шатландырган зур уңыш булды. Бу — станокта эшләүче иптәш Шакированың катлаулы детальләр эшләп чыгаруда гүзәл күрсәткечләр бирүе. Иптәш Шакирова эш вакытының һәрбер минутын дөрес файдалануы, станокны оста җайлап, интрументны рациональ төстә куллануы нәтиҗәсендә бер көнне 1.800 урынына 3.825 деталь эшләп чыгарды. Ул смена нормасын 216 процентка үтәп, бу өштә хатын-кызлар арасында рекорд куйды.

Иптәш Шакирова моннан соңгы көннәрдә дә темпын киметмәде. Аның фамилиясе цехның мактау тактасындагы исемлектә беренче булып тора.

—◇—

### Статистик конденсаторлар батареясы

Казан тимер юлының Юдино подстанциясендә 1943 нче елның башында статистик конденсаторлар установкасы куелган иде. Бу көч коэфициентын шактый арттырды, 1 нче кварталда ук 14 мең сумлык экономия бирде. Электр энергиясенә күчергәндә, бу 170 мең киловатт сәгать тәшкил итә. Чама белән исәпләгәндә батарея елына миллион киловатт сәгать электр энергиясенә экономия бирәчәк.

Н. Г.



Ключи МТС ындагы курсларны тәмамлап чыккан күп кенә яшь тракторчылар быел беренче тапкыр трактор руленә утырачаклар. Рәсемдә: курсларда укытучы тракторчы иптәш Г. Фәтхуллин үзенең укучыларына трактор моторының төзелешен аңлата.

К. Тахтеев фотосы.

## ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕСЕ—ОРЛЫК

Арча районы язгы чәчүгә әзер булудан ерак тора әле. Биредә орлык туплау бары 70 процентка гына үтәлгән.

— Орлык туплауны 80 процентка җиткерә алабыз инде аны. Әмма калган ягы турында берничек тә әйтә алмыйм.

Райком секретаре иптәш Александров әнә шулай ди. Иптәш Александровның сүзләрен болай аңларга кирәк: 7.352 гектар җирне чәчелми калу язмышы көтә.

Бу җитди мәсьәлә буенча нинди конкрет чаралар күрелде соң?

Районда орлык туплау уникөнлеге үткәрелде. Ләкин бу уникөнлек сугышчан төс алмады. Колхоз председательләре дә, райком работниклары үзләре дә моңа бер кечкенә кампания итеп кенә карадылар. Мәсәлән, райком работникларыннан Лотфуллин һәм райкомның агитация-пропаганда бүлеге мөдире Габитов иптәшләр «Кызыл яз» колхозында булдылар. Алдынгылар рәтендә саналган шушы колхоз членнарыннан бары 3 центнер 24 килограмм орлык җыелды. «Известия» колхозында Казанбаш МТС ы политбүлек начальнигы иптәш Николаев үзе утырды. Биредә дә колхозчылардан бары 2 центнер гына орлык җыелды. Ә бит бу колхозның 300 центнер орлыгы җитми.

Мондый мисалларны дистәләрчә санарга мөмкин. Шулай итеп, уникөнлектә районда бары 559 центнер орлык җыелды.

Язгы чәчүгә әзерлек эше орлык туплау белән башлана. Орлыгың бар икән, әзерлекнең иң кыен өлеше хәл ителде дип санарга мөмкин. Орлыгың ярым-ярты икән, яисә ул яраксыз икән, башка барлык әйберләрең хәзер булса да, язгы чәчүне куркыныч астына куючы, киләчәк уңышны куркыныч астына куючы, балаларың һәм дәүләтең каршында җинаятьче син. Моны аңлаган кешеләр авыр хәлдән чыгарга юл эзлиләр һәм табалар. Мәсәлән, «Завет Ильича» колхозында 50 процент орлык җитешми иде. Колхоз председателе иптәш Кузнецов бу хакта колхозчылар белән киңәште. Колхозчылар үзләренең запасларын тәкъдим иттеләр. Аннары отход дип саналган ашлыкны чистартып алдылар. Нәтиҗәдә колхоз чәчүлек орлыгы белән тәэмин ителде.

Кеше үз-үзенә дошман түгел бит. Колхозчы үз җирләрен чәчелми калдыруга ничек юл куя алсын. Арча районында шушы иң әһәмиятле эш—орлык туплау эше буенча аңлату эшләре гафу ителмәслек начар куелган. Колхозчылар арасында, бригадаларда эшлекле беседалар үткәрелмәгән. Стена газеталары чыгарылмаган. Хәтта район газетасының да декадага багышланган номеры декада ахырында гына чыкты.

Тагын 10—15 көннән сабан өсте. Колхозларда язгы чәчүгә әзерлек буенча сугышчан смотр декадасы игълан ителде. Әзерлекнең иң әһәмиятлесе—орлык. Арча районы җитәкчеләре өчен бу декада чәчүлек орлыгын тулысынча туплап бетерү һәм чәчүгә тулысынча әзерләнү декадасы булырга тиеш.

А. ЮНУСОВ.
«Кызыл Татарстан» ның махсус хәбәрчесе.

## ИКЕ КОЛХОЗ ЯРЫШЫ

Колхозларда социалистик ярышның көчәйгәннән-көчәя барган вакыты хәзер. Мулланур Вахитов исемендәге һәм Кече Кибәхуҗа колхозлары да үзара ярышалар. Алар язгы чәчүгә әзерлекнең торышына смотр үткәрелү уңае белән бер берсенең эшен тикшереп карарга булдылар.

Тикшерү көне билгеләнде. Бу көнне вахитовчылар Кече Кибәхуҗа колхозына бик иртә килделәр. Ревкомиссия председателе Биктимеров һәм агротехник Шаһиев иптәшләр күптән инде биредә. Бу колхозның җитәкчеләрен тикшерү планы белән таныштырганнан соң, алар бергәләп эш участокларына киттеләр. Тимерчелектә, амбарларда, ат абзарларында булдылар. Чәчү машиналарының, сабаннарның, тырмаларның һәрбер частен тикшереп үттеләр. Чәчү орлыгын карадылар. Колхозчы актив белән сөйләштеләр.

— Уңышлы эшләр тиз күренә ул, менә җитешсезлекләр турында сөйләшик диделәр күрше колхоздан килүчеләр.

Чыннан да, колхозның 62 арбасының 30 ы гына төзек, 50 сабанның 43 е генә әзер, 48 тырманың 28 е генә ремонтланган. Бер культиваторны да төзәтәсе бар әле. 3 нче бригадада валеклар җитешми. 1 нче һәм 2 нче бригадаларда тырмалар җитәрлек түгел. Агротехника чараларының үтәлеше бик түбән. 205 центнер көл урынына бары 48 центнер, 90 центнер урынына 60 центнер кош тизәге тупланган. Җыелган көлне саклау урыны начар. Анда кар кергән һәм көл суланган. 1 нче һәм 3 нче бригаданың ат абзарындагы тирес кырга чыгарылмаган. Атларның хәле дә уртадан түбән.

Икенче көнне вахитовчылар янына Кече Кибәхуҗа агротехнигы Таҗиева һәм 4 нче бригаданың бригадиры Мөхәммәтшин иптәшләр килделәр. Бу колхозда да шактый күп җитешсезлекләр ачылды.

Чәчү орлыгы җитәрлек. Ләкин аның саклануы хуҗасызлыкны күрсәтә. Борчак һәм вика орлыклары калын катлаулар белән салыну сәбәпле, дымлылыкның проценты зур. Орлык салынган амбарлар тирәсендәге кар көрәлмәгән, канаулар ясалмаган. Шунлыктан амбарга су керү куркынычы бар. Чәчү машиналарының ящиклары бер җирдә, станнары икенче урында таркау хәлдә. Ике сабанның көпчәкләрендә втулкалар юк.

Кич белән ике колхозның да комиссия членнары Казаклар авыл советы бинасына күчмә утырышка килделәр. Табылган кимчелекләр турында актлар төзелде. Җитешсезлекләрне бетерү юлларын күрсәтеп, аны үтәү срогы 3 нче апрельгә билгеләнде.

И. ЗАХАРОВ,
М. ХАФИЗОВА.
Теләче районы.

## КОЛХОЗЧЫЛАР БУЛЫШЛЫГЫ БЕЛӘН

ЮТАЗЫ, 2 апрель. **(Телефон буенча).** «Игенче № 1» колхозы орлык туплау декадасына кушылып, бик яхшы уңышларга ирешә: хәзер ул үзен чәчүлек орлык белән тулысынча тәэмин итте һәм үзеннән арткан орлыкны (6.060 пот) күрше колхозларга бирде. Башка колхозларга бирелгән бу орлыкның шактый өлеше колхозчы хуҗалыклардан керде. Мәсәлән, колхоз члены иптәш Насыров 42 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде. Идрисов 36 пот ашлык, 12 пот бәрәңге, Галимов С. 30 пот ашлык, 18 пот бәрәңге, Фарукшина Х. 24 пот ашлык бирделәр.

«Яңа юл» колхозы да күрше колхозларга 582 пот ашлык һәм 786 пот бәрәңге бирде. Колхоз члены иптәш Хәмидуллин бу фондка 60 пот ашлык, 18 пот бәрәңге кертте.

Хәзер бу колхозларда язгы чәчүгә әзерлекне тикшерү декадасы башланды

## Колхозларның ОРЛЫК ФОНДЫНА

### *Совет патриотлары взносы*

118. **ГАЙНЕТДИНОВ И.**—Кукмара районы, «Красный Октябрь» колхозы члены —58 пот бәрәңге бирде.

119. **ВӘЛИЕВА Ф.**—Әлмәт районы, «Эльком» колхозы члены, фронтовик хатыны—18 пот ашлык бирде.

120. **ШӘИХОВ Х.**—Азнакай районы, «Шатлык» колхозы члены—72 пот ашлык кертте.

121. **ТРАВКИН И.**—Баулы районы, «Большевик» колхозы члены —30 пот ашлык һәм 15 пот бәрәңге бирде.

122. **ГАЙФЕТДИНОВ**—Аксубай районы, «Кызыл юл» колхозы члены—9 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде.

123. **ЯППАРОВ З.** — Минзәлә районы, «Үрнәк» колхозы члены—38 пот ашлык бирде.

124. **ХАТИПОВ Х.** — Азнакай районы, «Көрәш» колхозы члены—93 пот ашлык бирде.

125. **ХӘМИДУЛЛИН С.**—Ютазы районы, «Яңа юл» колхозы члены —60 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге бирде.

126. **ГЫЙЛАҖОВ С.**—Тымытык районы, «Каен күл» колхозы члены—31 пот ашлык бирде.

127. **ЛЕДОМСКАЯ Е.** — Шөгер районы, «Ленинский путь» колхозы члены—31 пот ашлык бирде.

128. **АБДУЛЛИН Л.**—Азнакай районы, «Шатлык» колхозы члены —60 пот ашлык бирде.

129 **ТӨХФӘТУЛЛИН Л.** — Буденный районы, «Гигант № 2» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде.

130. **МИФТАХОВ Х.**—Калинин районы, «Нептун» колхозы члены —30,5 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

131. **ШӘЙХЕТДИНОВ М.**—Азнакай районы, «Большевик» колхозы члены—36 пот ашлык бирде.

## КОМИССИЯ ЭШКӘ КЕРЕШТЕ

БАУЛЫ, 2 апрель. **(Телеграф буенча).** Нәриман исемендәге колхоз (председателе иптәш Сабиров) шушы көннәрдә язгы чәчүгә әзерлекне тәгәлләгән иде. Колхоз барлык культуралар буенча орлык белән тулысынча тәэмин ителде. Орлыклар җентекләп чистартылган һәм алар һәрьяктан югары кондицияле.

Агротехника чараларын үткәрү буенча да эш уңышлы барды. 201 гектар мәйданда кар тотылды. Басуга 1.557 йөк тирес чыгарылды, 32 центнер көл һәм 20 центнер кош тизәге җыелды.

Атларның көрлеге әйбәт. Аларны тәрбияләүгә хәзер аеруча нык игътибар бирелә. Авыл хуҗалыгы машиналары, инвентарьлар һәм сбруйлар барысы да төзек. Агротехника түгәрәгендә укучылар язгы кыр эшләренә өйрәнүне тәгәлләделәр инде. Бу эшләр аларга практик рәвештә күрсәтелде.

Колхозчылар хәзер үз хуҗалыкларындагы запасларыннан күрше колхозлар өчен орлыклык ашлык җыялар. 74 пот ашлык һәм 111 пот бәрәңге җыелды инде.

Язгы чәчү вакыты килеп җитә. Димәк, аңар әзерлек тәгәлләнгән булырга тиеш инде. Кечкенә генә кимчелек тә калмаган булырга тиеш. Шуңар күрә биредә чәчүгә әзерлекне тикшерү декадасы үткәрүне бик яхшы каршы алдылар һәм шул көнне үк комиссия төзелеп эшкә керешә.

ГАЛЯВИЧ.



Кара диңгез флоты. Рәсемдә: «Парижская коммуна» линкоры палубасында вахтадан соң.
ТАСС фотохроникасы.

С. УРАЙСКИЙ

## *Яз көткәндә*

(Сугышчы блокнотыннан)

Киң кырларга тиздән язлар килер,
Дулкынланыр Идел ташкыны;
Дулкынланып Идел ташкынындай
Язны көтә күңел ашкынып.

Язлар килер тиздән, матур язлар,
Чәчәкләнер кырлар, урманнар,
Җылы яктан кайтыр сандугачлар
Һәр таң саен сайрый торганнар.

Киң кырларга тиздән язлар килер,
Сугыш давылы узган җирләрдә
Колхоз басуын тутырып бодай үсәр
Дулкынланып искән җилләрдә.

Язлар килер иркен далаларга,
Язлар килер безнең болынга,
Эраклардан китеп җырлар, яңгырар,
Сылу кызлар чыгар уенга.

Язлар килер тиздән, матур язлар
Чәчәкләнер кырлар, урманнар,
Ераклардан китеп җырлар, яңгырар,
Сәхра, кырлар йотылып тыңларлар.

Снарядлар, туплар тавышы тынар,
Дошман явын җиңгән батырлар,
Сугыш кырларыннан—
Туган илгә
Дан һәм мактау алып кайтырлар.

Язлар килер тиздән, матур язлар...
Мин ул көнне әгәр күрмәсәм,
Энҗе чыклы яшел болыннарда
Сезнең белән бергә йөрмәсәм,
Беләм,
Сөйгән ярым сезнең арагызда
Иң кадерле кунак саналыр,
Тантаналы бәйрәм, кичләреңең
Түрләрендә аңар урын калыр.
Хөрмәт белән зурлап каралыр.

Без биредә фашист кабахәтне
Кызганусыз кискән урында,
Гомерем язы сулган чәчәк төсле
Өзелеп калса сугыш кырында,

Яшьли үлгән сугышчының яры
Үткәрмәс ул гомерен кайгырып,
Монаймас һәм ямансуламас
Якын дусларыннан аерылып.

Киң кырларда тиздән
Язлар килер,
Дулкынланыр Идел ташкыны,
Дулкынланып Идел ташкынындай
Язны көтә күңел ашкынып.

—◆—

### Кызылармеец семьяларына ярдәм

Кызылармеец семьяларына ярдәм итү буенча Апас районында соңгы вакытта шактый нәрсәләр эшләнде, 545 семьяга 160 центнер ашлык белән, 1.769 семьяга 2 928 кубометр утын белән ярдәм күрсәтелде. Шулай ук күп кенә кызылармеец семьяларына ярдәм тәртибендә мануфактура, өс, аяк киемнәре бирелде.

Кызылармеец семьясы Тәнзилә Сәмитовага район оешмалары ярдәме белән өй салып бирелде. «Мәгариф» колхозы правлениесе фронтовик хатыны Ибәтуллина һәм Вәлиуллина иптәшләргә берәр тана бирде. Чапаев исемендәге колхоз снайпер иптәш Исламов семьясына ярдәм тәртибендә бер тана бирде.

М. ЗАҺИТ.

## ГРЕЦИЯ ХАЛКЫ ОККУПАНТЛАР КАРШЫНДА ТЕЗ ЧҮКМИ

ИСТАМБУЛ, 1 апрель. (ТАСС). Грециядә Германиягә һәм Италиягә каршы хәрәкәт үсә. Бөтен Грециядә грекларны Германиягә эшкә җибәрү өчен оккупантларның мобилизацияләвенә җиккен каршылык күрсәтергә чакыра торган яшерен листовкалар таратыла. Афинада һәм Пирейда йортларның стеналарында «Бетсен немецлар!», «Фашистларга эшләгәнче үлү яхшырак!», «Немецлар игълан иткән мобилизацияне өзегез!» дигән бик күп язулар күренә. Март урталарында Афинада күп кеше катнашкан демонстрация булган, демонстрациядә меңнәрчә эшчеләр һәм Афина университеты студентлары катнашкан. Итальян гаскәрләре демонстрантларны куарга маташканнар. Кораллы бәрелешләр булган. Нәтиҗәдә күп кешеләр үтерелгән һәм яралангән. Демонстрациядә катнашучы күп кешеләр кулга алынган.

Шулай ук Афинада политик забастовка булган. Забастовкада шәһәрдәге һәм аның тирә-як районнарындагы барлык предприятиеләрнең эшчеләре, шулай ук хезмәткәрләрнең күп өлеше катнашкан.

Һәркайда да Германиягә каршы саботаж актлары яшая. Күптән түгел, Афинадагы авиаремонт заводында ремонт ясалган немец самолетларының моторларын бозганнар. Шуның нәтиҗәсендә берничә самолет беренче очуда ук ватылып төшкән. Бер группа патриотлар Саламина атавының Кулури шәһәре тирәсендәге биеклекләрдә немецларның зенит һәм прожектор установкаларын җимергәннәр. Орудиеләрнең һәм прожекторларның бер өлеше бик югарыдан ыргытып ташланган. Немецларның гаепле кешеләрне табарга тырышуларыннан бер нәтиҗә дә чыкмаган. Гитлерчылар, ачуларыннан нәрсә эшләргә белмичә, якындагы авылның бернәрсә дә гаепләре булмаган кешеләрен атып үтергәннәр һәм аларның үле гәүдәләрен Кулури урамнарына асып куйганнар.

## Туниста сугыш хәрәкәтләре

ЛОНДОН, 31 март. (ТАСС). Рәсми хәбәргә караганда, кичә самолетлардан ату нәтиҗәсендә, Удерфа белән Сфакс арасындагы юлда дошманның кимендә 50 мотоповозкасы юк ителгән һәм 300 мотоповозкасы зарарланган. Һава сугышларында дошманның 20 самолеты бәреп төшерелгән.

Рейтер агентлыгы немецларның тизлек белән төньякка таба чигенүләрен хәбәр итә. Хәзер Роммельнең төп бурычы—төньяктагы Арним гаскәрләре белән кушылу. Ихтимал, Роммель Бизерта—Тунис линиясендә нытып урнашырга маташыр.

Марет позицияләрендә Роммель карамагында немецларның 2 танк дивизиясе, 1 җинел бронетанк дивизиясе. бер пехота дивизиясе һәм итальяннарның берничә дивизиясе бар иде. Сугышта төп удар немецларга төшкән һәм шуның аркасында аларның кешеләр һәм материаллар югалтулары аеруча күп булырга тиеш.

ЛОНДОН, 1 апрель. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы гаскәрләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, Гафса районында союзниклар гаскәрләре дошманга атака ясауларын һәм алга баруларын дәвам иттерәләр. Бронетанк көчләреңең алга баруына мина кырлары тоткарлык ясый. Фронтның Төньяк участогында хәзер союзниклар гаскәрләре Серженанены үтеп киткәннәр һәм уңышлы рәвештә алга баруларында дәвам итәләр. Дошманның бик күп сугыш милекләре кулга төшерелгән.

Төньяк Африкадагы француз гаскәрләре штабының хәбәр итүенә караганда, фронтның көньяк участогында Шатты—Җәридтән төньяктарак хәрәкәт итүче француз частьлары Әлгаттардан көньяк-көнчыгышка таба 10 миль алга киткәннәр. Дуздан хәрәкәт итүче «дөя корпусы» Кебилигә якынлашып килә.

Рейтер агентлыгының Әлгаттардан көнчыгыштагы районда Америка гаскәрләре янындагы махсус хәбәрчесенең язуынча, Америка танклары 12,5 миль алга китеп, Габеска бара торган юл белән Кебилидән Шатты—Әлфәҗеж аркылы төньякка таба бара торган юл кушылган пунктка килеп җиткәннәр.

Фронтның төньяк участогында генерал Арним командалыгындагы Германия гаскәрләре март башында күп корбаннар биреп алынган территориядән чигенәләр.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, хәзер 8 нче армия частьлары яр буендагы коридор алдында соңгы тоткарлык булган Габес аралыгында күчәр державаларның оборана позицияләре каршында торалар. Немецлар тиз чигенү мөмкинлеге алу өчен бу коридорны үз кулларында тотарга маташалар.

### НЕАПОЛЬДӘ ЗУР ШАРТЛАУЛАР

ЖЕНЕВА, 31 март. (ТАСС). 28 нче мартта Неапольдә зур шартлаулар булган. Сугыш припасларь склады шартлаганлыгы Римда рәсми рәвештә игълан ителгән. Шартлау нәтиҗәсендә 72 кеше үлгән һәм 1.179 кеше яраланган. Шартлауның нәтиҗәләрен тикшерү өчен махсус комиссия төзелгән.

### Германиянең чит ил эшләре министрлыгы работникларын җәзалап үтерү

ЛОНДОН, 31 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы моннан берничә көн элек Германиянең чит ил эшләре министрлыгының 3 чиновнигы җәзалап үтерелгәнлеген хәбәр итә. Аларның исемнәре әйтелмәгән. Алынган хәбәрләргә караганда, алар «дошман белән элемтә тотуда гаепләнгәннәр. Кайберәүләрнең әйтүенчә, бу кешеләр Гитлерга каршы яшерен җәмгыятьнең члennары булганнар.

ИНДИВИДУАЛЬ БАКЧАЧЫЛАРГА КИҢӘШ

## ЮГАРЫ УҢЫШ АЛУГА МИН НИЧЕК ИРЕШТЕМ

Шәһәр хезмәт ияләре арасында индивидуаль һәм коллектив бакчачылыкны җәелдерү азык ресурсларын арттыруда бик нык ярдәм итә. Сугыш вакытында аның нинди әһәмиятле булуын сөйләп торасы юк.

Бакчадан югары уңыш алу өчен зур көч куярга кирәк. Җир участогы биләп торып та, аннан уңыш алмаучылар үзләре өчен дә, дәүләт өчен дә начар эшлиләр. Кайбер кешеләр «минем эшем чәчү, уңышны җир үзе үстерә» дип карыйлар. Бу караш һич тә дөрес түгел. Аның дөрес түгеллеген без үзебезнең практикада бик ачык күрдек. Безнең бер-берсенә янәшә торган участоклардан төрле кеше төрлечә уңыш җыеп алды. Җиргә хезмәт күрсәткән иптәшләр югары уңыш алуга ирештеләр, аз көч куйганнары уртача уңыш алдылар, ә инде «җир үзе үстерер әле» дип көтеп ятканнары чәчкән орлыкларын да җыеп ала алмадылар.

Мин, башка иптәшләр кебек үк, бәрәңгене шактый соңга калып утыртсам да үз участогымнан аларга караганда күп тапкырлар артык уңыш җыеп алдым. Югары уңыш алуга мин ничек ирештем соң?

Иң элек вакыт турында әйтеп китәргә кирәк. Без күбебез вакыт юк дип зарланабыз. Теләк булса вакыт табарга мөмкин икән. Мин бик еш кына иртәнге сәгать 2 дә, 3 тә торып участокка бара идем. Ял көннәренең күбесен диярлек шунда уздыра идем. Бу, җиргә кирәк булган хезмәтне күрсәтергә, көчне куярга мөмкинлек бирде.

Мин 300 квадрат метрлы җир алдым. Вакыт соң булганлыктан, аны алдан эшкәртергә һәм ашларга туры килмәде. Аның каравы инде утыртканда һәм үскән чагында күп эшләргә кирәк булды. Минем чәчүлек материалым уртача әрелектәге бәрәңгедән, вак бәрәңгедән һәм кисентеләрдән тора иде (шунысы характерлы, уңыш бөтен бәрәңгегә караганда кисентеләрдән күбрәк алынды). Кисентеләрне күзәнәк саннарына карап, һәрбер төпкә икешәрне салдым. Шунда ук төпләрне йомшарта бардым. Төпләрнең бер берсеннән 55—60 сантиметр ара калдырдым. Бәрәңге сабагы күренә башлагач, җирен тырмаладым һәм бер үк вакытта чүп үләннәрен дә йолкып ташладым. Бәрәңге сабагы 5—7 сантиметрга күтәрелгәч, җирне тагын йомшарттым, яңа гына чыгып килүче сабакларны күмеп китмәслек итеп төпләрен өйдем. Чәчәк ата башлауга рәт араларын эшкәртүгә һәм икенче тапкыр төп өюгә керештем. Моны мин болай эшләдем: тамырларга тидермәс өчен, саклык белән генә җирне казыдым, казыганда туфракны астын өскә әйләндермичә җиңелчә генә күтәрдем. Моннан соң инде, сабакка зыян килмәслек итеп, тырма белән җирне йомшарттым. Бу эш сабанның тиз үсеп китүенә мөмкинлек бирде. 2—3 көннән соң инде минем участоктагы бәрәңгеләр үзләренең куелыклары белән башкалардан аерылып тора иде. Бәрәңге чәчәк атканнан соң берникадәр вакыт яңгыр булмый торды. Бу вакытта дым бик кирәк иде. Моны аңлаган хәлдә мин берничә тапкыр су сибеп чыктым. Менә шушы эшләрнең барысы нәтиҗәсендә мин кечкенә генә участоктан 9 капчык бәрәңге алдым. Безнең оешмадан берәү дә ул кадәр уңыш ала алмады.

Быел мин тагын да зуррак уңыш алырга тырышачакмын. Моның өчен җирне алдан эшкәртергә һәм ашларга, аннан соң утырткан әйберне яхшы тәрбияләп үстерергә кирәк. Бу эшләр өчен әзерлек башладым инде.

Шәһәрдәге һәрбер кеше индивидуаль бакчаларда тырышып эшләргә, бәрәңгедән һәм яшелчәдән югары уңыш алу өчен көрәшергә тиеш. Бу, хезмәт ияләрен азык белән тулысынча тәэмин итәргә, шуның белән тылыбызны ныгытырга, производствода тагын да яхшырак эшләп, кабахәт дошманны тар-мар итүдә Кызыл Армиягә булышлыгыбызны тагын да арттырырга ярдәм итәр.

Х. МАРЬЯХИН.

## Татарстанда

### ОПЕРА ТЕАТРЫНДА

Татар дәүләт опера һәм балет театрында композитор Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсын куюга әзерлек бара. Шагыйрь М. Җәлил либреттосы буенча эшләнгән бу операның декорациясе атказанган сәнгать эшлеклесе Сперанский тарафыннан эшләнде. Әсәрне уйнауда опера театрының барлык төп көчләре катнаша. Алар арасында атказанган артистка Мәрьям Рахманкулова, Зәбирова, Насретдинов һәм башкалар бар. Музыка бүлеге дирижер Старжиһанов тарафыннан алып барылачак. Операның балет бүлеге балетмейстер Гай Таһиров җитәкчелегендә әзерләнә. Шул уңай белән балет көчләре яшь кадрлар белән тулыландырылды.

«Алтынчәч» операсы Беренче Май бәйрәме көннәрендә куелачак.

Театрда шулай ук рус телендә «Русалка» операсын куюга да әзерлек башланды.

—◆—

СУД

### К. ДАВЫДОВ ЭШЕ

Шушы көннәрдә Татарстан АССР Верховный Судының күчмә сессиясендә Чаллы МТС ы трактор бригадасының элекке бригадиры К. И. Давыдовның эше каралды.

Гаепләнүче Давыдов МТС та эшләгән вакытында саботаж ясау юлына баскан. Ул, 1942 нче елның көзендә Чаллы районының Молотов исемендәге колхозында ашлык сукканда; усал ният белән машинаны ваттырып, сугу эшен өзгән. Нәтиҗәдә бу колхозда ашлык сугу бик соңга калган.

Давыдов кыш көне МТС та тракторларга ремонт ясауга дә игътибар бирмәгән, ремонтны яхшы итеп башкармаган. Ниһаять, ул, 9 нчы январьда эшне бөтенләй ташлап, авылына кайтып киткән. Аның тарафыннан ремонтланган радиаторлар яраксыз булып чыкканнар. Шунлыктан, аларга яңадан ремонт ясарга туры килгән.

Судта тикшерелгән материаллардан һәм шаһитләрнең күрсәтүеннән Давыдовның гаепле икәнлеге ачык мәгълүм булды. Давыдов 10 елга төрмәгә ябылуга һәм җәза срогын тутырганнан соң сайлау-сайлану хокукыннан 3 елга мәхрүм ителүгә хөкем ителде.

Җаваплы редактор
И. ҮЗБЕКОВ.

### ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 4 нче апрельдә—**«Патша кәләше»**.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 6 нчы апрельдә—**«Хуҗа Насретдин»**.

Зур драма театры. Бүген — **«Маскарад»**.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген Менжинский исемендәге клубта концерт. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

Дәүләт циркы. Бүген—3 бүлектә **зур цирк тамашасы**. Кич 8 сәгатьтә башлана.

«Электро»—иртә белән һәм көндез—**«Партизаннар Украина далаларында»**, кич— **«Истребительләр»**, «Унион» — **«Партизаннар Украина далаларында»**. «Пионер»—көндезге 1 сәгатьтә—**«Руслан һәм Людмила»**, кич—**«Дуслык»**. «Чаткы»—көндез — **«Дуслар»**, кич — **«Алтын таулар»**.

Татарстан тегермән трестының Казан район тегермән идарәсе **3 нче апрельдә** Казанка дагы тегермән буасының сутелүчәгән һәм Казанка суының агызып җибәреләчәген барлык оешмаларга һәм халыкка белдерә.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ 12362 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 607